| БАВЛИНСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

РЕШЕНИЕ КАРАР

05.02.2026 Баулы шәһәре № 24

Татарстан Республикасы Баулы шәһәр Советының «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 2023 елның 25 маендагы 97 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым Кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының (закон актларының аерым нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында»2025 елның 28 ноябрендәге 425-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Баулы шәһәр Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Баулы шәһәр Советының «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 2023 елның 25 маендагы 97 номерлы карарына (Баулы шәһәр Советының 2024 елның 12 апрелендәге 123 номерлы, 2024 елның 13 июнендәге 130 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен преамбуладан төшереп калдырырга;

1 пунктның 1) пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) физик затның Россия Федерациясе граждан-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә (законнарда билгеләнгән очраклардан тыш) һәм Россия Федерациясе Салым Кодексының 59 статьясындагы 1 пунктының 3 пунктчасында билгеләнгән очракларда вафат булган яисә вафат булган дип игълан ителгән көннән алып өч еллык срокның тәмамлануы».

2. Әлеге карар 2026 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы шәһәр Советының җирле үзидарә, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә, комиссия рәисенә йөкләргә.

Баулы шәһәр мэры,
шәһәр Советы рәисе И.И. Гозәеров